| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**29.12.2018 г.** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2833** |

2019 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 21 декабрендәге 1879 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрне тотуга кушымта итеп бирелгән чыгымнарны расларга.

2. "Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе тарафыннан расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

“2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында” 2018 елның 24 сентябрендәге №57-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы белән

- әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хүокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет " мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.В.Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Расланды
Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
29.12. 2018 г. № 2833

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**
**Зеленодольск муниципаль районы**
**гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**

| Гомуми белем бирү оешмаларының тибы һәм төркеме | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы Интернат | шәһәр җире | 89268 |
| | авыл җире | 90630 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җире | 135418 |
| | авыл җире | 139893 |